Мөслим

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениясе Мөслим авылы «Карлыгач» гомумустерешле балалар бакчасы**

# “Карлыгач” балалар бакчасының үткәне һәм бүгенгесе

**2020 ел**



# “Карлыгач” балалар бакчасының үткәне





Татарстан Республикасының Мөслим авылында, 1991 нче елның октябрь аенда дүртенче балалар бакчасы сафка бастырыла. Бакчаны Мөслимдә урнашкан СМУ оешмасы эшләп чыга. «Карлыгач» балалар бакчасы ике этажлы матур, җылы бина булып чыга. Бакчаның мөдире итеп, Зөлфия Гыймай кызы Нафикованы билгелиләр.



**Нафикова Зөлфия Гыймай кызы** Мөслимдә колхозчы гаиләсендә бишенче бала булып дөньяга килә. Мәктәпне бетереп Казан дәүләт университетында татар теле һәм әдәбияте бүлегендә белем ала. Укуны тамәмлагач Мөслим авылы «Кояшкай» балалар бакчасында, аннан соң «Ләйсән» балалар бакчасында тәрбияче-методист булып эшли. Соңрак Мөслим урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияте укытучысы булып эшли. Зөлфия Гыймай кызы мөдир тәҗрибәсен «Тиенкәй» яслесендә башлап җибәрә. «Карлыгач» балалар бакчасында өзлексез 23 ел мөдир вазыйфасын тугры башкарып, Зөлфия Гыймай кызы лаеклы ялга чыга.

Мөслим

«Карлыгач» балалар бакчасына балаларны 1992 нче елның январь аеннан җыя башлыйлар. Шушы вакытта эшкә 9 тәрбияче килә: Исламова Альфира Флюн кызы, Миннеханова Рәйсә Хәмит кызы, Фардеева Брилиант Миңнулла кызы, Хабирова Индира Риф кызы, Корбиева Дамира, Маликова Лилия Даннур кызы, Арсланова Лариса Николай кызы, Садыкова Раушания Мөгәмбәр кызы, Валиева Рәфинә Мөдәриф кызы.





Яңа төзелгән бакчаның әле эше күп була һәрбер бүлмәне җыештырырга, юарга кирәк, шуның өчен техник персонал җыялар: Назмиева Римма Ислам кызы, Шавалиева Роза Хәмит кызы, Камалетдинова Луиза Мизхәт кызы, Багаутдинова Һәдия Габдул кызы, Исламова Роза Зәки кызы, Мирзаянова Тәкыя Әхсән кызы, Каримова Миңлетәнзилә Ягъфәр кызы

# “Карлыгач” балалар бакчасының үткәне









**Фардиева Брилиянт Миңнулла кызы** 1957 нче елның 21 маенда Новокузнецк шәһәрендә туган. 11 яшендә гаиләсе белән Мөслимгә кайталар, мәктәпне шунда тәмамлый. Минзәлә медицина училищесында, соңрак Бөгелмә педагогия училищесында укый. 1976 нчы елдан шәфкать туташы булып эшли, 1988 елдан тәрбияче булып башта “Тиенкәй”, “Карлыгач” аннары “Кояшкай” балалар бакчасында үз эшен яратып башкара. 2015 нче елда лаеклы ялга чыга. 27 ел педагогик стажы бар. Гомуми эш стажы – 40 ел.



**Фардиева Лариса Вилин кызы**, 1975 елның 20 нче февралендә Минзәлә районы Воровский совхозында, колхозчы гаиләсендә туа. 1992 нче елны Тат. Шуран урта мәктәбен бетерә. 1994 нче елны Мөслимгә килеп үзәк хастәханәдә санитарка булып эшли. 2001 нче елда “Карлыгач” балалар бакчасына тәрбияче ярдәмчесе булып эшкә урнаша. Балалар бакчасында 11 ел эшли. Бүгенге көндә сәүдә өлкәсндә хезмәт куя.



**Шарафутдинова Лилия Даннур кызы.** 1967 елның 2 маенда Мөслим районы, Мөслим авылында дөньяга килә. Мөслим урта мәктәбенә 1984 елда тәмамлый. 1985 елда Мөслим урта мәктәбенә химия-биология кабинетында лаборант булып эшли башлый. 1986-1990 елларда Алабуга дәүләт педагогия институтында мәктәпкәчә белем бирү факультетына укырга керә. 1990 елда укуын тәмамлап, Мөслим районы, Мөслим аылының НПСка караган “Ромашка” балалар бакчасына тәрбияче булып эшкә керә. 1991 елда “Карлыгач” балалар бакчасына тәрбияче булып урнаша. 2006 елдан “Миләшкәй” балалар бакчасында укытучы-логопед булып эшли.



**Валиева Рафина Мудариф кызы** 1969 елның 23 августында Мөслим районы Каенсаз авылында колхозчы гаиләсендә дөньяга килә. 1988 елда Ташьелга авылына тәрбияче булып урнаша. 1991 елның декабрь аенда “Карлыгач” балалар бакчасында тәрбияче булып эшли башлый. 1998 елның апреленә кадәр шунда эшли. 1998-2005 елларда Коры сөт заводында мастер булып эшли. 2007 елда Татнефть АЗС үзәгендә оператор булып урнаша, хәзерге көндә дә шунда эшли.

# “Карлыгач” балалар бакчасының үткәне









**Шәрифуллина Раушания Рафаэль кызы** 1964 елның 10 декабрендә Мөслим авылында туа. 1986 елны Алабуга педагогия институтының мәктәпкәчә тәрбия бирү бүлеген бетереп Мөслим авылына эшкә кайта. Карлыгач балалар бакчасына 1994 елның ноябренда декрет ялыннан соң эшкә чыга һәм 2001 елга кадәр тәрбияче булып эшли. 2001 елны мәгариф идарәсенең әмере буенча ул Мөслим авылы Миләшкәй балалар бакчасына өлкән тәрбияче булып билгеләнә. Бу бакчада 2003 елга кадәр эшли. 2003 елның август аенда РОНОга эшкә күчә, биредә лаеклы ялга киткәнчегә кадәр эшли.

**Арсланова Лариса Николай** кызы1968 елның 22 ноябрендә Мөслим авылында туа. 1975 елда Мөслим авылының башлангыч сыйныфына укырга керә, урта белемне дә шул ук мәктәптә ала. 1986 елны Алабуга педагогия институтына укырга керә, биредә 5 ел укый. Институтны бетергәч чит илгә чыгып китәләр. 1991 елда Мөслим районына кайтып, “Карлыгач” балалар бакчасына эшкә урнаша. 1994 елда беренче мәктәпкә укытучы итеп эшкә чакыралар. 1997 елдан 2003 елга кадәр Мөслимнең 2нче мәктәбендә эшли. 2003 нче елдан 2015 нче елга кадәр гимназиядә рус теле фәнен укыта.2015 елда РОНОга эшкә чакыралар.





**Шәяхмәтова Земфира Габдрахман кызы** 1957 елның 29 мартында Мөслим авылында эшче гаиләсендә икенче бала булып дөньяга килә. 1972 елны сигезенче классны тәмамлап, Лениногорск педагогия училищесының музыка бүлегендә укый башлый. 1976 елда музыка тәрбиячесе белгечлеге алып, Мөслим балалар бакчасына эшкә кайта. 1977 елны эшен “Кояшкай” балалар бакчасында дәвам итә. 2008 елдан хезмәт юлын “Карлыгач” балалар бакчасында музыка җитәкчесе вазыйфасында башкара, 1990 елда “Халык мәгарифе отличнигы” мактау билгесенә лаек була. 2014 елдан лаеклы ялда.

**Рахматуллина Алсу Расих кызы** 1975 елның 20 нче маенда Салауз - Мухан авылында туган. 1990 нчы елны шушы авылда 9 нчы сыйныфны тәмамлап, Бөгелмә педагогия училищесына укырга керә. 1995 нче елны Метрәй урта мәктәбендә хезмәт юлын башлап җибәрә. 2001 - 2007 нче елларда "Карлыгач" балалар бакчасында тәрбияче булып эшли. 2007-2019 нчы елларда Мөслим гимназиясендә укытучы хезмәтен башкара. Хәзер Түбән Табын интернат мәктәбендә сәламәтлекләре чикле булган балаларны укытам.



# “Карлыгач” балалар бакчасының үткәне









**Габидуллина Илмира Мизхәт кызы,** 1961 елның 25 сентяберьндә Мөслим районы Иске Карамалы авылында дөньяга килә. 1979 елда Күбәк урта мәктәбен тәмамлый. 1979-1980 еллар Алабуга культура училищесында укый. 1981 елда Мөслим урта мәктәбенең башлангыч класслары өчен пионервожатый итеп билгеләнә. 1983 елда Сал.Мухан балалар бакчасына тәрбияче итеп күчерелә.1989-1992 елларда Түбән Кама педагогика училищесында укый. 1994 елда «Өлкән тәрбияче», 1998 елда «Тәрбияче методист», 2009 елдан «Югары категорияле» тәрбияче, 2002- 2016 елга кадәр «Карлыгач» балалар бакчасында тәрбияче булып эшли. 2016 елда лаеклы ялга чыга.

**Хафизова Чулпан Мизхәт кызы**, 1970 елның 26 августында Мөслим районы Иске Карамалы авылында дүртенче бала булып дөньяга килә. 8 нче сыйныфтан соң Түбән Кама шәһәренең педагогия көллиятенә укырга керә. 1989 нчы елда көллиятне тәмамлап Мөслим районының Әмәкәй авылы балалар бакчасына мөдир итеп эшкә җибәрелә. 1990 нчы елда Мөслим авылындагы “Миләшкәй” балалар бакчасында тәрбияче булып 11 ел балаларга белем һәм тәрбия бирә. 2001 нче елда “Карлыгач” балалар бакчасына эшкә күчә. “Карлыгач” балалар бакчасында 5 ел эшли. 2016 нчы елда “Кояшкай” балалар бакчасына күчә.





**Садикова Раушания Мөгәмбәр кызы** 1963 нче елда Мөслим авылында туа. 1980 елда Мөслим урта мәктәбен тәмамлаган. 1981 елда Мөслим районы Октябрь авылы "Ландыш" балалар бакчасына тәрбияче булып эшкә килә. 6 ай эшләгәч Алабуга культура агарту училищесының китапханәчеләр әзерләү бүлегенә укырга керә, училищены 1983 елда тәмамлап Октябрь авылына китапханә мөдире булып эшкә кайта. 1989 елда Мөслимгә район мәгариф бүлегенең методик кабинетында машинистка булып эшли. 1991 елда "Карлыгач" балалар бакчасына тәрбияче булып эшкә күчә. 2014 елга кадәр коллективны башлангыч профсоюз рәисе була. 2018 елда лаеклы ялга чыга

**Хабирова Индира Риф кызы** 1967 елның 28 сентябрендә Мөслим районы Иске Карамалы авылында туган. 1974 елда гаиләләре Мөслимгә күченеп килә. 1984 елда Мөслим урта мәктәбен тәмамлагач, Алабуга дәүләт педагогия институтында рус теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. 1989 елда институтны тәмамлагач, Мөслим районы Шуганка авылы мәктәбенә үз белгечлеге буенча укытырга кайта. 1990 елда Әмәкәй мәктәбенә рус теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшкә күчә. 1991 елда Мөслимдә “Карлыгач” балалар бакчасы ачылгач, тәрбияче булып урнаша. 2015 елда “Кояшкай” балалар бакчасына күчә һәм хәзерге көндә дә шунда эшли.



Мөслим

# “Карлыгач” балалар бакчасының үткәне









**Харрасова Флүрә Нурлыгаян кызы**, 1949 нчы елның 25 сентябрендә Мөслим районы Ике Вәрәш авылында колхозчы гаиләседә туган. 1967 нче елда Мөслим мәктәбен тәмамлый һәм Алабуга шәһәренең Мәдәният училищасына укырга керә. 1992 нче елда Яр Чаллы шәһәренең Педагогика институтына мәктәпкәчә педагогика һәм психология бүлегенә укырга керә. 1992-1993 нче елда логопед укытучысына квалификация үтә. 1993 нче елның 1 сентябрендә Мөслим “Миләшкәй” балалар бакчасында логопед – укытучысы булып эшли. 2001нче елда “Карлыгач” балалар бакчасына логопед- укытучысы булып күчерелә.

**Сафиуллина Гөлфия Яхъя кызы**, 1975 елның 26 мартында Мөслим авылында эшчеләр гаиләсендә туган. 1981 елда Мөслим мәктәбенә укырга кергән, мәктәпне 1992 елда тәмамлаган. 1992-1995 нче елларда Мөслим училищесында тәрбияче һөнәрен үзләштерә. 2001 елда “Карлыгач” балалар бакчасында тәрбияче булып эшли башлады. 2009 нчы елда “Кояшкай” балалар бакчасына күчә. 2020 нче елдан Түбән табын коррекция мәктәбендә эшли.





**Багаутдинова Хәдия Габдул кызы** 1940 елның 14 апрелендә Сарлы районы Югары Табын авылында туа. Балачак еллары шул авылда уза. Мәктәпнең 7 классын тәмамлый. Мөслим якларына килен булып төшкәч, 1972 елда “Тиенкәй” балалар бакчасына эшкә урнашып, шунда 19 ел эшли. 1991 елда “Карлыгач” балалар бакчасына тәрбияче ярдәмчесе булып эшкә керә. 1995 елда лаеклы ялга чыга.

**Мирзаянова Тәхия Әхсән кызы**,1945 елның 22мартында, Актаныш районы Луговой авылында, гади эшчеләр гаиләсендә туган. Актаныш районы,Семиостровка авылында урта белем мәктәбен тәмамлагач, авылда калып фермага эшкә урнаша. 1965 елда Актаныш районы Табанлы күл авылына кияүгә чыга, ике малай бер кыз үстерәләр. Мөслим районы, Мөслим авылында бытовойда, тегүче булып эшкә урнаша. 1990 елдан “Карлыгач” балалар бакчасына тәрбияче ярдәмчесе һәм тегүче булып эшли. 1997 елда лаеклы ялга чыга.



# “Карлыгач” балалар бакчасының үткәне









**Камалетдинова Луиза Мисхат кызы** 1955 елның 25 сентябрендә Мөслим районы Күбәк авылында дөньяга килә. Балачак һәм мәктәп еллары шул авылда уза. Югары белем алырга дип, Нижнекамск шәһәрендәге ГПТУ-44 училищесына укырга керә. Укуын тәмамлау белән “Шинни” заводында эшли. 1 ел эшләп, Мөслимгә кире кайта һәм 1977 елның 24 мартында “Кояшкай” балалар бакчасына эшкә урнаша. 1991 елның 26 октябрендә “Карлыгач” балалар бакчасына зав.хоз. булып эшкә керә. Хәзерге вакытта Луиза Мисхатовна лаеклы ялда.



**Каримова Тәнзилә Ягъфар кызы** 1959 елның 20 августында Мөслим районы Симәк авылында колхозчы гаиләсендә туа. 1966 елны 1нче сыйныфка укырга керә. 1976 елда мәктәпне тәмамлый. 1976- 1981 елларда Симәк мәктәбендә сәнгать җитәкчесе булып эшли. 1991-1992 елларда Мөслим “Айгөл” балалар бакчасында тәрбияче булып урнаша. 1992 елның маеннан “Карлыгач” балалар бакчасында тәрбияче булып эшли башлый. 1998 елда повар булып күчә. 2014 елның сентябрьендә лаеклы ялга китә.

Мөслим



**Шәвәлиева Роза Хәмит кызы** 1960 елның 7 нче ноябрендә Бәләкәй Чакмак авылында туа. 3 сыйныф белемне туган авылында ала, 8 нче сыйныфка кадәр күрше Мухан авылына йөреп укый. 9-10 нчы сыйныфны Мөслимдә тәмамлый. Түбән Кама шәһәренә техникумга укырга керә, Шина ясау заводына эшкә урнаша, укуын тәмамламый. Хезмәт баскычын Мөслим авылы “Тиенкәй” балалар бакчасыннан башлап җибәрә. “Карлыгач” балалар бакчасы ачылуга, бирегә эшкә урнаша. 2008 нче елда авария нәтиҗәсендә көчле җәрәхәт ала, хезмәт юлын туктатырга туры килә. Бүгенге көндә лаеклы ялда.



**Нәҗмиева Римма Ислам кызы** Актаныш районы Бишкүмәч авылында туа. Башлангыч белемне Югары Яхши авылында ала (8 сыйныф), тагын ике ел Киров совхозында укый һәм 1980 елда Мөслим районына килә. Кияүгә чыга. 1980 елда “Ясле”гә эшкә урнаша. 1992 нче елда “Карлыгач” балалар бакчасы ачылуга, кер юучы штатына эшкә урнаша. 2018 нче елга кадәр хезмәт куеп, лаеклы ялга чыга.

# “Карлыгач” балалар бакчасының үткәне









**Петрәева Елена Миңлегәрәй кызы**, Мөслим районы, Калтак авылында 1960 елнын 8 сентяберендә туа. Сигез еллык мәктәпне тәмамлагач, Нижнекамск шәһәрендә укый һәм штукатур моляр булып эшли. Мөслимгә кайткач та штукатур моляр шөгелен дәвам итә. 1993-1996 елны “Карлыгач” балалар бакчасына пешекче булып урнаша. Бугенге көндә лаеклы ялда.



**Камалова Фәнүзә Марс кызы**, 1967 елның 5 нояберендә Мөслим районы Нарат-асты авылында 4 нче бала булып дөньяга килә. Әти- әнисе гомер буе ”Кызыл октябрь” колхозында эшләп лаеклы ялга чыктылар. 1985елда Мәллә-Тамак урта мәктәбен тәмамлап Чаллы шәһәрендә Камаз заводында эшли. 1989 елда Мөслим районы Иске Вәрәш авылына кияүгә чыга.1990 елда игезәк кызлары туа. 1992 елда “Карлыгач” балалар бакчасына эшкә керә. Анда 2007 елга кадәр тәрбияче ярдәмчесе булып эшли.



**Суфиахметова Гөлсинур Хәниф кызы** 1960 нчы елнын 23 нче октябрендә Мөслим районы Бәкәбее авылында туган. 1975 нче елда Октябрь сигезьеллык мәктәбен тәмамлагач Минзәлә педагогия училищесына укырга кереп аны 1979 нчы елда тәмамлап Мәллтамак урта мәктәбенә башлангыч класс укытучысы булып эшли башлый. 1984 нче елда Алабуга педагогия институтын тәмамлап Октябрь сигезьеллык мәктәбенә математика укытучысы булып килә. 1989 нчы елда “Кояшкай” балалар бакчасында тәрбияче булып эшли. 2011 нче елда “Карлыгач” балалар бакчасына тәрбияче булып эшкә урнаша. Бүгенге көндә лаеклы ялда.

**Шамгунова Рүзилә Вил кызы** 1973 нче елның 25 нче июлендә, Татарстан Республикасы Мөслим районы Мөслим авылында туган. Татар. 1981 нче елның сентяберендә Мөслим урта мәктәбенә укырга керә. 1989 нчы елда Түбән Кама шәһәрендәге СПТУ – 53 уку йортына контролер-кассир һөнәренә укырга керә. 1992 нче елда Мөслим районы “Карлыгач” балалар бакчасына тәрбияче ярдәмчесе булып эшкә урнаша. 1993 нче елны Түбән Кама педагогия училищесына читтән торып укырга керә. 1994 нче елда “Карлыгач” балалар бакчасында тәрбияче булып эшли башлый. 1995 нче елда шушы ук балалар бакчасында музыка укыта. Сәламәтлеге начараю сәбәпле 1998 нче елда эштән китәргә туры килә.



# “Карлыгач” балалар бакчасының үткәне









**Давлетшина Мәфрүзә Закир кызы** 1958 нче елның 18 нче октябрендә, Татарстан Республикасы Мөслим районы Горбуновка авылында колхозчы гаиләсендә туа. Авылдагы тугыз еллык мәктәпне тәмамлап, 1979 нче елда Мөслимгә күченеп килә, ХППга эшкә керә. 2006 нчы елда “Карлыгач” балалар бакчасында эшли башлый. 7 ел эшләп лаеклы ялга чыга.



**Давлетшин Радик Нәҗип улы** 1957 нче елның 8 нче октябрендә Мөслим районы Яңа Сәфәр авылында колхозчы гаиләсендә икенче бала булып туа. Авылдагы мәктәпне тәмамлап, 1974 нче елда Мөслимдәге СПТУга укырга килә. 1976 нчы елда армияда хезмәт итә. 1979 нче елда Мөслим авылына күченеп килә. ХППга эшкә кереп, анда тракторист булып эшли. Аннары “Карлыгач” балалар бакчасына эшкә урнаша һәм шуннан лаеклы ялга чыга.



**Валиева Гүзәлия Риф кызы** 1964 елның 10 февралендә Иске Вәрәш авылының колхозчылар гаиләсендә туа. 1971 елда Иске Вәрәш авылының башлангыч сыйныфына укырга керә. Белемне Мөслим мәктәбендә дәвам итә. Мәктәпне тәмамлагач “Тиенкәй” балалар бакчасында, аннан “Миләшкәй” балалар бакчасында эшли. Яңадан “Карлыгач” балалар бакчасына эшкә чыга һәм лаеклы ялга чыкканчы шунда эшли.



**Фазлиева Лилия Кәшбетдин кызы** 1966 нче елның 16 маенда Вәрәшбаш авылында өченче бала булып дөньяга килә. 1973 нче елны Вәрәшбаш авыл мәктәбенә укырга керә. Беренче эш көнен дә Вәрәшбаш авылы балалар бакчасында башлап җибәрә, аннан шунда ук мәктәптә укытучысы булып эшли. 1991 нче елны Мөслим авылы “Миләшкәй” балалар бакчасына эшкә керә. 2007 нче елны “Карлыгач” балалар бакчасында эшен дәвам итә. Хәзерге вакытта Мөслим авылы спорт мәктәбендә эшли.

Мөслим

# “Карлыгач” балалар бакчасының үткәне









**Султанова Миләүшә Әзхәр кызы**, 1969 елнын 17 гыйнварында, Кустанай өлкәсендә Амангелдин районы Родник авылында гади эшчеләр гаиләсендә дөньяга килә. 1986 елда мәктәпне тәмамлап, Казан дәүләт педогогика институтына француз - немец булегенең чит телләр факультетына укырга керә.1991елда укуны тәмамлап Югары Табынга эшкә кайта.1992-1997 елларда Мөслим урта мәктәбендә, француз немец телләрен укыта. 1999-2003 елларда Мөслимдә “Кояшкай”, ”Карлыгач” балалар бакчаларында педагог - психолог булып эшли. 2003 елнын 16 апреленнән “Кояшкай” балалар бакчасында мөдир булып эшли.



**Харисова Ләйсән Мирдәвис кызы** 1975 елның 19 ноябрендә Мөслим районы Яңа Карамалы авылында туа. Башлангыч белемне Кубәк урта мәктәбендә ала.1993 елда Алабуга дәүләт педагогия институтының филология бүлегенә татар теле, әдәбияте һәм чит телләр укытучысы белгечлеге буенча укырга керә. Кубәк урта мәктәбенә немец теле укытучысы булып эшкә урнаша. 2001 елда район үзәгенә “Кояшкай” балалар бакчасына тәрбияче, “Карлыгач” балалар бакчасына педагог-психолог булып эшкә күчә. 2003 елдан “Карлыгач” балалар бакчасында нәниләр төркеме җыеп, тәрбияче булып эшли башлый. 2014 елда Мөслим үзегендә урнашкан “Миләшкәй” балалар бакчасына мөдир итеп билгеләнә. Бүгенге көнгә кадәр шунда хезмәт куя.



**Заянова Лилия Рафис кызы** 1979 нчы елнын 15 нче августында Мөслим районы Метерәй авылында игезәк кызлар булып дөньяга килгән.1996-2000 нче елларда Лениногорск педагогия училищесының музыка факультетын тәмамлап, 2000-2005 нче елларда читтән торып Мәскәү дәүләт мәдәният сәнгать университетында югары белем ала. 2000-2003 нче елларда Мөслим районы “Миләшкәй” балалар бакчасында музыка җитәкчесе. 2003-2008 нче елларда «Карлыгач» балалар бакчасында музыка җитәкчесе булып эшләде. 2000 нче елдан бирле, хәзерге көндә Мөслим лицеенда музыка укытучысы булып эшли.



**Фәрхетдинова Гөлнар Валериянт кызы**, 1985 елның 15 декабрендә Мөслим районы Мөслим авылында туган.1993нче елда Мөслимнең 2нче санлы урта мәктәбенә 1нче сыйныфка укырга керә. 2004 елда мәктәпне тәмамлагач, Алабуга мәдәният училищесының режиссура бүлегенә укырга керә. 2007 елда укуны тәмамлагач, Мөслимгә кайта. 2007 елда – 2012 елга кадәр Мөслим почта бүлегендә эшли. 2012 елда Мөслим архивына- делопроизводитель булып эшли. 2013 елда – Мөслим “Ләйсән” балалар бакчасында тәрбияче ярдәмчесе булып эшли. 2014 елда - Мөслим “Карлыгач” балалар бакчасына музыка җитәкчесе булып эшкә керә.

Мөслим

# “Карлыгач” балалар бакчасының үткәне







Мөслим



# “Карлыгач” балалар бакчасының бүгенгесе






2019 елда көтеп алган капиталь ремонт керде. Аның өчен 19 млн. 700 мең сум акча бирелде. Бакчаның фасад белән түбәсе эшләнде, тәрәзә ишекләр, бөтен коммуникациялар алыштырылды, идән - түшәмнәр дә яңартылды. Бакча территориясы тигезләнде сукмакларга брусчатка җәелде. Бүгенге көндә бакчада 25 хезмәткәр эшли, шуларның 10 сы педагоглар. 4 төркемдә 88 бала йөри. Бакчада музыка залы, тренажер һәм юл иминлеге бүлмәләре бар.

**Фазлиева Гөлнур Фәрит кызы** 1977 нче елнын 3 нче апреленда Мөслим авылында туа. 1994 нче елны Мөслим урта мәктәбен тәмамлагач Яр Чаллы педагогия институтына укырга керә. 1996 нчы елда читтән торып уку бүлегенә күчеп Мөслимгә кайта. 2000 нче елда институтны тәмамлагач 2001 нче елда “Милшәкәй” балалар бакчасында тәрбияче ярдәмчесе, тәрбияче булып эшли башлый. 2002 нче елда “Миләшкәй” һәм “Ләйсән” балалар бакчасында педагог психолог вазыйфасын башкара. 2005 нче елдан 2012 нче елга кадәр мәктәптән тыш эшләр узәгендә педагог психолог булып эшли. 2012 нче елнын июнь аеннан “Ләйсән” балалр бакчасына вакытлыча мөдир итеп билгелиләр.2014 нче елнын январь аеннан “Карлыгач” балалар бакчасында мөдир булып эшли.



Мөслим

# “Карлыгач” балалар бакчасының бүгенгесе









**Садретдинова Гөлнара Роберт кызы** 1965 елнын 6 августында, Мөслим авылында туа. 1972 елда Мөслим урта мәктәбендә укый башлый. 1982 елда мәктәпне тәмамлагач, Чаллы шәһәренең медицина училищесына укырга керә. 1984 елда училищены тәмамлап, Мөслим үзәк больницасына эшкә урнаша. 1987 елда “Ләйсән” балалар бакчасына тәрбияче булып эшкә керә. 1991 елда Мөслим «Карлыгач» балалар бакчасына, шәфкать туташы итеп күчерелә. Бүгенге көндә югары категорияле шәфкать туташы булып эшли.

**Шаяхметова Зөһрә Вәзир кызы** 1983 нче елның 20 маенда Мөслим районы Мәллә – Тамак авылында, колхозчылар гаиләсендә өченче бала булып дөньяга килә. Мәллә – Тамак урта мәктәбен тәмамлагач Минзәлә авыл хуҗалыгы техникумында бухгалтер – экономист һөнәрен үзләштерә. Техникумны тәмамлагач, Мәллә – Тамак авылы мәдәният йортында мөдир булып эшли. 2006 нчы елда Мөслим авылы 60 нчы номерлы үзәк даруханәсендә, 2008 нче елда Яр Чаллы шәһәре “Dixis” сәүдә челтәрендә эшли. 2010 нчы елда Мөслим авылы “Ләйсән” балалар бакчасына эшкә килә. 2014 нче елда “Карлыгач” балалар бакчасына эшкә күчә, бер ел тәрбияче булып эшләгәннән соң, өлкән тәрбияче итеп билгеләнә. Бүгенге көндә дә “Карлыгач” балалар бакчасында хезмәт куя.



Мөслим

# “Карлыгач” балалар бакчасының бүгенгесе







Мөслим



**Харисова Ләйсирә Индус кызы** 1971 елның 4 январенда Мөслим районы Әмәкәй авылында гаиләдә өченче бала булып туган. 1978 елда Әмәкәй урта мәктәбенә укырга керә. 1986 елда сигезенче классны тәмамлап, Минзәлә педагогия училилищесында укуын дәвам итә. Аны 1990 елда тәмамлап, Мөслим районы Салавыз-Мухан авылында башлангыч сыйныфларда үзенең хезмәт юлын башлый. 1993 елда Әмәкәй урта мәктәбендә башлангыч сыйныфта укытып, 1995елдан Яр Чаллы шәһәрендә үзенең хезмәт юлын татар теле укытучысы булып дәвам итә. 1999-2004 еллар аралыгында читтән торып Казан дәүләт педагогия университетының филология факультетын тәмамлый. 2007 елдан Мөслимдәге “Карлыгач” балалар бакчасында тәрбияче булып эшли.



**Шәмсетдинова Әлфизә Рәфәт кызы** 1989 елның 15 июнендә Азнакай районы Әгерҗе авылында туган. Әгерҗе авылының урта белемле мәктәбен тәмамлап, 2006 елда Әлмәт шәһәренең Физкультура техникумына укырга керә. 2008 елда югары белем алырга дип, “Восточная экономико-юридическая гуманитарная академия” институтына укырга керә. Мөслимгә кайтып, хәзерге вакытта “ Карлыгач” балалар бакчасында тәрбияче булып эшли.



**Карамова Гөлнара Илгиз кызы**, 1984 елның 23 апрелендә Төмән өлкәсе Нефтеюганск шәһәрендә эшчеләр гаиләсендә туа. 7 нче сыйныфны тәмамлагач Мөслим районы Иске Карамалы авылына гаиләсе белән күченеп кайталар. 2001 нче елда Күбәк урта мәктәбен тәмамлый. Шул ук елны Яр Чаллы Дәүләт Педагогика Институтына татар филология факультетына укырга керә. 2009 нчы елда Иске Карамалы авылында балалар һәм яшүсмерләр өчен "Наз" социаль приютында тәрбияче булып эшли башлый. 2015 нче елны "Күбәләк" балалар бакчасына тәрбияче булып күчә. 2016 нчы елда "Карлыгач" балалар бакчасында эшли башлый һәм бүгенге көнгә кадәр шунда эшли.



**Корбангалиева Чулпан Әнәс кызы**, 1989 елның 5 нче декабрендә Мөслим районы Мөслим авылында туган. 1997 нче елда Мөслимнен 2 нче санлы урта мәтәбенә 1нче сыйныфка укырга керә. 2008 нче елда мәктәпне тәмамлагач, Яр Чаллы педагогика көллиятендә мәктәпкәчә белем бирү бүлегендә белем ала. 2011нче елда педагогика көллиятен тәмамлагач, Яр Чаллы шәһәрендә “Тургай” исемле балалар бакчасында тәрбияче булып эшли. 2019 нчы елда – Мөслимгә кайтып “Карлыгач” балалар бакчасына тәрбияче булып эшкә керә.

Мөслим

# “Карлыгач” балалар бакчасының бүгенгесе









**Гайнетдинова Лениза Мират кызы** 1985 елның 5 сентябрьендә Мөслим районы, Мөслим авылында туа. 2001 елны 9 нчы сыйныфны тәмамлап, Муса Җәлил исемендәге Минзәлә педагогия көллиятендә укый башлый. 2005 елны көллиятне тәмамлап, юллама нигезендә Әлмәт шәһәре “Кар кызы” балалар бакчасына тәрбияче булып урнаша. 2006-2010 елларда Мөслим районы Мөслим “Кояшкай” балалар бакчасында вакытлыча төрле урыннарда эшли. 2012 елда тәрбияче булып күчерелә. 2015 елда “Күбәләк” балалар бакчасына тәрбияче булып күчә. 2016 елда “Карлыгач” балалар бакчасында тәрбияче булып эшли башлый. Бүгенге көндә дә шунда хезмәт куя.

**Монасыпова Рәзилә Рөстәм кызы**, 1979 елның 9 январендә Мөслим районының Октябрь авылында туа. 1985 нче елда мин Мөслим авылындагы башлангыч мәктәбенең беренче сыйныфына укырга керә. Урта мәктәптә 9 нчы сыйныфны тәмамлый. 1995 нче елда Минзәлә педагогия көллиятенә укырга керә. Көллиятне 1999 нчы елда тәмамлап, Бөгелмә шәхәренә эшкә китә. Анда татар теле укыта. Бөгелмәдә 1 ел эшләгәннән соң Мөслим районына эшкә кайта. 2006 нчы елда НГПИ ны тәмамлй. 2015 нче елда Мөслим районының “Карлыгач” балалар бакчасына тәрбияче булып урнаша.





**Гильмутдинова Лилия Вәкил кызы** 1981 нче елның 24 октябрендә Мәскәү шәһәрендә туа. 1988 нче елда Мәскәүнең 456 номерлы мәктәбенә 1 сыйныфка укырга керә. 5 сыйныфта укыганда гаиләсе белән Яр Чаллы шәһәренә күченеп китәләр һәм укуны шул шәһәрдә дәвам итә. 1996 нчы елда ПУ 67 һөнәри училищесында пешекче һөнәрен үзләштереп “Океан” ресторанына эшкә урнаша, 2 ел дәверендә шунда пешекче булып эшли. 2014 нче елның май аенда Мөслим “Карлыгач” балалар бакчасына хуҗалык мөдире булып эшкә урнаша. 2018 нче елда Яр Чаллы дәүләт педагогика университетында укуын бетереп “Карлыгач” балалар бакчасында тәрбияче булып эшли башлый.

**Бәдертдинова Гөлназ Илгизәр кызы** 1986 нчы елның 26 нчы сентяберендә, Татарстан Республикасы Мөслим районы Олы Чакмак авылында туган. Татар. 1993 нче елның сентяберендә Олы Чакмак төп гомуми белем бирү мәктәбенә укырга керә. 2004 нче елда Мөслим гимназиясенең 11 нче сыйныфын тәмамлый. 2004 елда Яр Чаллы дәүләт педагогия институтының мәктәпкәчә белем бирү һәм психология бүлегенә укырга керә. 2010 нчы елда укуны тәмамлый. 2009 нчы елның 1 нче декаберендә Мөслим районы “Карлыгач” балалар бакчасына эшкә урнаша.



Мөслим

# “Карлыгач” балалар бакчасының бүгенгесе









**Фазлыева Елена Фирдәвес кызы**, 1982 елның 1гыйнварында, Мөслим районы Шуганка авылында, гади эшчеләр гаиләсендә икенче бала булып дөньяга килә. 1988-1999 елларда Шуганка авылы урта белем бирү мәктәбен тәмамлый. 2003 елда авылда сатучы булып эшли. 2006 елда Мөслимдә “Тугай” кибетенә сатучы булып эшкә урнаша. 2018 елдан Мөсимдәге “Карлыгач” балалар бакчасында хуҗалык мөдире булып эшли.



**Аптеева Ирина Тимеркаевна**, 1973 елның 10 февралендә Мөслим районы Мари-Бүләр авылында туа. 1980 нче елда Мари-Бүләр мәктәбенең 1 сыйныфына укырга керә. Урта белем алу турында аттестат ала. 1988-1989 нчы елларда Мөслим районы Симәк авылында 9-10 сыйныфларны тәмамлый. 1990 елдан 1992 елга кадәр Мөслимдә “Тиенкәй” балалар бакчасында эшли, 2001 елдан бирле “Карлыгач” балалар бакчасында эшли.



**Халиуллина Ләйсән Тимерхан кызы** 1976 елнын 25 мартында Мөслим районы Дусай авылында гади эшчеләр гаиләсендә туа. 1982-1991елда Дусай авылы мәктәбендә белем ала. 1991-1994 елда һөнәри белем алу училищесына пешекче кондитер профессиясен сайлап укырга керә. 2009 елда “Карлыгач” балалар бакчасына пешекче булып эшкә керә.



**Сабитова Румия Тимур кызы**, 1967 елнын 13 июлендә Мөслим районы Дусай авылында гади эшчеләр гаиләсендә дуртенче бала булып туа. 1974-1984 елда мәктәпне бетереп, калхозда эшли. 1990-2002 елда “Миләшкәй” балар бакчасына тәрбияче ярдәмчесе булып эшли. 1994 елда Бөгелмә мәктәпкәчә педогогик училищесын бетереп диплом ала. 2016 елда “Карлыгач” балалар бакчасына пешекче ярдәмчесе булып эшкә керә.

# “Карлыгач” балалар бакчасының бүгенгесе







# “Карлыгач” балалар бакчасының бүгенгесе



**Шайхетдинова Фәйрүзә Хәбип кызы** 1969 нчы елның 6 августында Мөслим районы Олы Чакмак авылында дөньяга килә. 1986 нчы елда мәктәпне тәмамлый. 1988 елда Бөгелмәдә кооперативный училищесында белем ала. 1991 елда Бөгелмә педагогик училищесында укый.1990 нчы елдан 1996 нчы елга кадәр “Кояшкай” балалар бакчасында эшли. 1996 нчы елдан 2005 нче елга хәтле ХПП да эшли. 2005 - 2006 га хәтле Мөслим үзәк больницасында эшли. 2006 нчы елның 9 октябреннән башлап “Карлыгач” балалар бакчасында эшли.

**Магданурова Эльвира Шамиль кызы** 1984 нче елның 22 нче июлендә Мөслим районы Шуганка авылында калхозчы гаиләсендә өченче бала булып дөньяга килә. 1990 нчы елда Шуганка урта мәктәбенә укырга керә. 2000 нче елда укуны тәмамлай. Ике ел авыл кибетендә сатучы булып эшли. 2002 нче елда Мөслим авылына күченеп килә. 2003 нче елда “Арыш мае” кибетендә эшли. 2006 нчы елда “Карлыгач” балалар бакчасына тәрбияче ярдәмчесе булып эшкә керә.





**Фархетдинова Гөлназ Госман кызы** 1976 елның 14 декабрендә Мөслим районы Октябрь авылында эшче гаиләсендә туа. 1994 нче елда Октябрь урта мәктәбен тәмамлый. 1998 нче елда Минзәлә педагогия көллиятен тәмамлап, Октябрь урта мәктәбенә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшкә билгеләнә. 1999 – 2001 нче елларда Бәкәбез, 2001 – 2002 нче елда Елгабаш башлангыч мәтәбендә башлангыч класслар укытучысы булып эшли. 2002 елда Түбән Кама шәһәренең 86 нчы номерлы балалар бакчасында тәрбияче булып эшли. 2003 нче елдан Иске Карамалы авылында “Наз” социаль приютында тәрбияче булып эшли. 2014 нче елның  август аена “Карлыгач” балалар бакчасына тәрбияче ярдәмчесе булып эшкә урнаша.



**Смелова Ирина Николай кызы** 1975 елның 3 июлендә Мөслим районы Мөслим авылында туа. 1982 елда Мөслим урта мәктәбенә укырга керә. 1990 елда 9 сыйныфны тәмамлап СПТУ- 94 уку йортына тәрбияче белгечлеге буенча укырга керә. 1993- 1999 елда укуын бетергәч, мәктәптә техник эшче булып эшли башлый. Аннан декрет ялына китә. 2002 елда мәктәптә  техник эшче булып эшләвен дәвам итә.  2014 елга кадәр шунда эшли. 2014 елның август аеннан “Карлыгач” балалар бакчасына тәрбияче ярдәмчесе булып урнаша, бүгенге көндә дә шунда эшли.

# “Карлыгач” балалар бакчасының бүгенгесе



**Марданова Гөлфинә Мирхәйдәр кызы** 1970 нче елнын 8 нче сентяберендә Мөслим районы Каенсаз авылында туа. 1987 нче елда мәктәпне тәмамлагач “Авангард” колхозына эшкә керә. 1988 нче елда пешекче булып эшли башлый. 2002 нче елда Мөслим училищысын тәмамлап Мөслим мәктәбендә, 2019 нчы елдан “Карлыгач” балалар бакчасында пешекче булып эшли башлый.



**Кондратьева Римма Решат кызы** 1986нчы елнын 10 октябрьнда Мөслим районы Иске Вәрәш авылында колхочы гаиләсендә туа. 1994 елда Мөслим мәктәбенә укырга керә. 2003 елда ПУ-94 уку йортына повар-кондитер һөнәренә укырга керә. Укуны тәмамлагач белгечлеге буенча ООО “Строймелосервис” оешмасына эшкә урнаша. 2011 елда Мөслим «Картлар һәм инвалидлар» оешмасына няня булып эшкә керә. 2019 елда Мөслим авылы «Карлыгач» балалар бакчасына тәрбияче ярдәмчесе булып эшкә урнаша.

# “Карлыгач” балалар бакчасының бүгенгесе







Мөслим

# “Карлыгач” балалар бакчасының бүгенгесе





